# *БИЕКТАУ РАЙОНЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕ*

# *ЗНАМЕНИТЫЕ ЛЮДИ ВЫСОКОГОРСКОГО РАЙОНА*

# Әхмәтһади Максуди



**Әхмәтһади Максуди** — XX гасырның беренче чирегендәге татар дөньясында иң укымышлы зыялыларыбызның берсе. Аны үз заманында ук «иң-иңнәрнең», ягьни иң танылган шәхесләрнең беренче унлыгына керткәннәр. Ул — татар әлифбасына 6 хәреф кертеп, «имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дип уку-укыту системасын яңача укыту юлына кертеп җибәрүчеләрнең берсе, — 1906 елдан башлап 1918 елга кадәр чыгып килгән иң күп тиражлы «Йолдыз» гәзитенең нәшир-редакторы, XX йөз башы татар милли хәрәкәтендә танылган җәмәгать эшлеклесе.Һади Максуди — Әхмәтһади Низаметдин улы Максудов 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Ташсу авылы (хәзерге Биектау районына керә ) мулласы гаиләсендә туган. Низаметдин мулла гаиләсе татар дөньясына ике олуг шәхес — Һади һәм Садри Максудиларны биргән.Әхмәтһади башта үз авылындагы әтисе мәдрәсәсендә укый. 1881 елны ул Казанга килә, заманының мәшһүр мәдрәсәләренең берсе булган «Күл буе» яки «Галләмия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм сигез ел дәвамында шунда белем ала. Укып бетергәч — 1890-92 елларда шунда ук мөгаллимлек итә. Мәдрәсәләрдәге укыту системасын үзгәртү кирәклеген иртә аңлаган яшь мөгаллим 1892 елда татар мәгарифендә чын мәгънәсендә инкыйлаб ясаган, ягьни татар әлифбасына 6 хәреф кертеп, һәм «Имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дигән кагыйдәсеннән файдаланып, үзенең «Мөгаллим әүвәл» әлифбасын бастырып чыгара. Әлеге дәреслек 1918 елга кадәр барлыгы 32 басма кичерә, татар балалары өчен генә түгел, ә казакь, башкорт, кыргыз, үзбәк балаларының да уку китабы булуы белән уникаль күренешкә әйләнә.

1893 елда ул Төркиягә китә һәм андагы яңа ысул белән укыту системасы белән таныша, татарча гәзит чыгару уе белән янып йөргән Һ. Максуди анда гәзитчелек серләренә дә өйрәнә. Монда ул төрек язучысы Ж. Мидхәт белән таныша, «Икьдам» гәзите редакторы белән дуслаша, хәтта бераз вакыт әлеге гәзиттә эшләп тә ала. Төркиядән кайтышлый ул, И.Гаспринский чакыруы буенча, Кырымда Бакчасарайда туктала, андагы Зынҗырлы мәдрәсәсендә укыта, «Тәрҗеман «гәзитендә эшли.

1896 елны Һ. Максуди Казанга кайта һәм Казан укытучылар мәктәбендә экстерн юлы белән имтиханнар тапшырып укытучы дипломы ала. 1897 елда «Бертуган Юнысовлар» химаясындагы мөселман балалар приютында татар теле, тарихы һәм җәгърәфия фәннәрен укыта. Ул бу елларда яңача дәреслекләр язу һәм мөгаллимлек итү белән шөгыльләнә. 1913 елның июнендә исә гәзиткә Г.Баттал эшкә килә һәм ул 1917 елның җәенә кадәр сәркәтиб булып эшли. Ул эшләгән чорда «Йолдыз» гәзитенең тиражы 6-7 меңгә җитә. Октябрь инкыйлабыннан соң башланган эзәрлекләүләр, татар зыялылары язмышы Һ. Максудины да читләтеп узмый, 3 елга Вятка шәһәренә сөргенгә җибәрелә.Һ. Максуди сөргендә үзенең гыйльми эшчәнлеген ташламый. Сөрген срогы тулганнан соң, 1936 елның ахырында Һ.Максуди Казанга кайта. Ләкин ул иректә озак яши алмый. 1937 елның гыйнварында тагын шул ук контрреволюцион эшчәнлектә гаепләп аны кабат кулга алалар. 1938 елның 10 гыйнварында Һ.Максудига ачылган «Эш», сәламәтлеге бик начарлану сәбәпле, туктатыла һәм 1939 елның 2 февральдә ябыла. Аңа, шулай итеп, хөкем карары чыгарылмыйча кала. Төрмәдән чыккач, Һ.Максуди инде озак яши алмый, ул 1941 елның 28 июнендә вафат була. Кабере Яңа Бистә зиратында, Тукай кабере белән янәшә.

Ахмад Хади Максуди (1868-1941) без преувеличения можно назвать одним из самых важных просветителей татар первой четверти 20 века. Самым главным делом всей его жизни стало языкознание.

Ахмад Хади Максуди родился 28 сентября 1868 года в деревне Ташсу Казанского уезда Казанской губернии (ныне Высокогорский район республики Татарстан) в семье муллы Низамутдина. Эта семья дала татарскому народу двух великих сыновей - Ахмад Хади (Хади) и Садретдина (Садри) Максуди.Свое первое образование Ахмад Хади получил в деревенском медресе отца в Ташсу. После этого в 1881 году он приехал в Казань, где поступил в знаменитое “Приозерное медресе” (медресе “Касимия”) при Апанаевской мечети. Закончив обучение в 1890 году, Ахмад Хади Максуди остался в своей альма-матер, где два года преподавал у учеников младших классов. Жизнь в Казани дала ему возможность познакомиться с русским и европейским просвещением в целом. И Ахмад Хади стал задумываться о причинах отсталости мусульманского образования, которое к тому времени не успевало за научными и экономическими переменами, происходившими в мире. Ему самому на практике удалось увидеть неэффективность старых методов обучения и в том числе необходимость реформирования татарского арабографического письма (“иске имлә” - старое письмо). Так, в 1892 году Ахмад Хади Максуди выпустил свой легендарный учебник-букварь “Мугаллим авваль” (“Первый учитель”).Для удобства чтения и письма в учебнике “Мугаллим авваль” в существующий алфавит Ахмад Хади Максуди впервые добавил дополнительные буквы, обозначающие некоторые гласные звуки (о, ө, ә). Данная книга стала настолько популярной, что с 1892 по 1918 годы она была издана 32 раза, а общий тираж книги составил более 1 миллиона экземпляров. В начале 20 века “Мугаллим авваль” стал одним из лучших пособий для освоения чтения и письма на татарском языке на основе арабской графики. Чуть позже Ахмад Хади Максуди издал продолжение учебника-букваря - “Мугаллим сани” (“Второй учитель”), который уже обучал чтению и письму на арабском языке. Однако общественность не сразу приняла идеи А. Максуди по реформированию алфавита. В 1890-е годы у него появилось сильное желание издавать свою газету. Он много раз обращался в Главное управление по делам печати с просьбой получить разрешение на издательскую деятельность, однако каждый раз получал отказ. Лишь после революции 1905 года, которая предоставила всем народам Российской империи свободу слова и печати, ему наконец-то удалось осуществить свою мечту. И 15 января 1906 года вышел первый номер его газеты “Юлдуз” (“Звезда”). Дальнейшая судьба Ахмад Хади Максуди сложилась трагически. После революции он дважды подвергался репрессиям. Первый раз был арестован 16 января 1933 года за якобы антисоветскую деятельность, шпионаж в пользу Турции и тайную связь с татарскими эмигрантами - своим братом Садри Максуди, Гаязом Исхаки и Фуатом Туктаровым. Арест закончился ссылкой в Вятку на три года. Даже в ссылке он продолжал работать - написал труд “Восточная логика” и перевел его на русский язык. В 1936 году после окончания ссылки он вернулся домой. Однако на свободе пришлось быть недолго. В январе 1937 года его вновь арестовали по обвинению в контрреволюционной деятельности. Несмотря на пытки и унижения, Ахмад Хади Максуди не признал своей вины. Через два года, 2 февраля 1939 года, связи с ухудшением здоровья и отсутствием состава преступления дело было прекращено. Но годы, проведенные в тюремных застенках, не прошли бесследно и окончательно подорвали его здоровье, на свободу он вышел больным и измученным человеком... На свободе он смог прожить всего лишь два года. Ахмад Хади Максуди умер 28 июня 1941 года и был похоронен на мусульманском кладбище Ново-Татарской слободы, недалеко от могилы Габдуллы Тукая.



**Садри Максуди**

Садретдин Низаметдин улы Максудов (Садри Максуди Арсал, 1878-1957) – Русия һәм соңрак Төркия сәясәтчесе, Идел-Урал штатын оештыруны җитәкләүче.
Казан губернасының Казан уезды Ташсу авылында (хәзерге Татарстанның Биектау районы) 1878 елның 23 июлендә татар мулласы гаиләсендә дөньяга килә. 1888 елдан башлап Казанда урнашкан Апанаев мәдрәсәсендә укый. 1893 елда Бакчасарайда Исмәгыйль Гаспринскийның Зынҗырлы мәдрәсәсендә укый (анда аның абыйсы Әхмәтһади Максуди укыта). Әтиләре 1894 елда вафат булганнан соң, Казанга кайталар. 1901 елга кадәр Садри урыс укытучылар мәктәбендә укый. Гаспринский киңәше белән Парижга укырга китә, 1901-1906 елларда Париж университетының юридик факультетында укый, хокук фәннәре кандидаты исемен ала. Баштарак тормышы бик ярлы булса да, Париж газетына хәбәрче булып урнаша, Русия мөселманнары турында лекцияләр укый башлый.1906 елда Казанга кайтып сәяси эшчәнлеген башлый, "Иттифак әл-Мөслимин" оешмасына кушыла, татарларның һәм башка мөселман халыкларның хокукларын яклау эшенә керешеп китә.Дәүләт Шурасы да төзелә. Бәйсез Идел-Урал Штатын оештыру эше башлана, аның җитәкчесе итеп Садри Максуди сайлана. Әмма большевиклар Идел-Урал Штатын төзергә мөмкинлек бирми. 1918 елның апреленә большевиклар Дәүләт Шурасы эшчәнлеген тыя. Татар милләтчеләренең җиңелүеннән соң Максуди Финляндиягә китә.1919 елда Париж (Версаль) солых конференциясендә Максуди Гаяз Исхакый белән бергәләп Русиянең Европа өлешендә яшәүче мөселманнарның таләпләрен дипломатик нота буларак җиткерә. 1920нче еллар башында ул Берлинда фәнни эшчәнлеккә керешә һәм аны 1925 елда Анкарага күченгәч тә дәвам итә.
Вакытлыча Парижда яшәгән арада Максуди Сорбонна университетында төрки халыклар тарихын укыта башлый. Әмма 1924 елда Төркиягә лекцияләр укырга килгәч, Максудиның тормышына зур үзгәреш керткән вакыйга була. 1925 елда ул чактагы Төркия президенты Мостафа Кемаль Ататөрек аны Төркиягә күченеп килергә чакыра. Төркиядә Максуди күпьяклы фикер иясе, хокук, тарих, фәлсәфә, лингвистика һәм социология өлкәләрендә эшләүче галим, яңа барлыкка килүче Төркия Республикасы төзелешенә бик зур һәм мөһим өлеш кертә.Парижда хокук белгечлегенә укыган Садри 1925 елда ачылган Анкара хокук мәктәбенә нигез салучыларның берсе була. Әмма аның хокук белеменә керткән иң мөһим эше университетта Төрек хокукы тарихы дигән дәресләрне башлау була. Бу дәресләр хәзер Төркиядә хокук факультетларының стандарт дәресләренә әверелә. Ул биредә төрек телен реформалауда да катнаша, парламент әгъзасы да була. 1939-1950 еллар арасында һәм 1954 елдан соң үзен тулысынча фәнни эшчәнлеккә багышлый.
Садри Максуди Арсал 1957 елның 20 февралендә 78 яшендә Истанбулда дөнья куя һәм Истанбулның Зинҗирликую зиратында җирләнә.

Садри Максуди Арсал родился в 1878 году в селе Ташсу близ Казани , Российская Империя . После окончания учительского института в Казани в 1900 году он отправился в Стамбул, где оставался на некоторое время. Два года спустя Арсал отправился учиться в университет Сорбонны , где в конце концов получил степень магистра юридических наук. Вернувшись в Россию, он вступил в Исламскую конституционную партию. Арсал был представителем Казанского округа во второй Думе в 1907 году и в третьей - в 1908 году. Позже Арсал был избран президентом недолговечного Идель-Уральского государства. До этого он был председателем народного собрания, проходившего в Уфе в 1917 году по данному государству. В 1918 году, после подъема большевизма и распада исламской партии, частью которой он был, Садри Максуди Арсал бежал через Санкт-Петербург в Финляндию , где остановился в Тампере , в доме местного финского татарина по имени Имад Самалетдин. Оттуда в следующем году он продолжил свою поездку в Париж , где на Мирной конференции он выступал за политические права людей, живущих в районе Идель-Урала , хотя он не смог добиться положительного результата своей речью. В 1922 году Садри Максуди Арсал ненадолго вернулся в Финляндию, потому что его семья бежала туда из Советского Союза . Вместе они отправились в Германию , поселившись в Берлине . Живя там, Арсал в основном занимался историческими исследованиями и воздерживался от какой-либо политической деятельности. Через некоторое время он переехал в Париж, где читал лекции по истории Турции на славянском факультете Сорбонны. В 1925 году Арсал переехал в Турцию , где, среди прочего, работал лектором, а затем профессором истории права и философии в университетах Анкары и Стамбула, и в конце концов был удостоен почетного звания. Садри Максуди Арсал опубликовал множество литературных работ в областях, в которых он учился, например, Türk dili için , в котором рассматривается развитие турецкого языка и в котором он предлагает различные способы его улучшения; как удаление с него посторонних влияний. Арсал был избран членом турецкого парламента на три законодательных периода. Он умер в 1957 году в Стамбуле.



**Галимҗан Баруди**

Мәшһүр дин галиме, җәмәгать эшлеклесе, күренекле педагог, Үзәк Диния нәзарәтенең мөфтие Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Баруди (Галиев) 1857 елның февраль башында Казан өязенең Кече Кавал авылында (хәзерге Татарстанның Биектау районында) сәүдәгәр гаиләсендә туа. 1860 елда гаилә Казанга күчеп килә.1862 елда Галимҗанны Апанай мәдрәсәсенә укырга бирәләр.Биредә ул Саләхетдин хәзрәт Исхаковта белем ала, мөстәкыйль рәвештә күп китаплар укый. Тырышлыгы, сәләте зур булу сәбәпле, 1871 елда башлангыч сыйныфларда дәресләр бирә башлый. 1875 елда белемен күтәрү өчен 18 яшьлек Галимҗан Урта Азиягә юл тота. Анда җиде ел укып, дини һәм дөньяви фәннәрне үзләштерә.1882 елның 15 июнь көнендә яшь галим Казанга күп китаплар һәм кульъязмалар белән кайта. Бу багажның авырлыгы якынча 650 кг, бәясе 5-6 мең була. Галимҗан Баруди гомер буе китап җыю белән шөгыльләнә. 1920 елда Галимҗан Баруди үзенең уникаль китапханәсен дәүләткә тапшыра. Бу байлык хәзерге көндә Казан (Идел буе) федераль университе-тының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана.1882 елның 28 октябрендә Галимҗан хәзрәт Иске татар бистәсенең бишенче Җәмигъ мәчетенең (хәзерге Тукай урамындагы Галиев мәчете) имамы итеп билгеләнә. Мәчет каршында дәресләр бирә. Тиздән Галимҗан хәзрәтнең үз мәдрәсәсендә белем бирү мөмкинлеге барлыкка килә. 1882 елда әтисе тарафыннан мәдрәсәнең бер катлы бинасы төзелә. Әлеге мәдрәсәдә Галимҗан Баруди 1883 елда беренче дәресләр бирә башлый. Бу мәдрәсә аңа нигез салган Мөхәммәтҗан исеменә нисбәт ителеп «Мөхәммәдия» исемен ала. Шәкертләрнең саны елдан ел арта бара. Шуңа күрә Мөхәммәтҗан Галиев танылган татар сәүдәгәрләре Әхмәтҗан Сәйдәшев һәм Габдулла Үтәмишев белән мәдрәсәне зурайталар. 1886 елда мәдрәсә бинасының өченче каты салына. Мәдрә-сәнең даны киң тарала.1886 елдда Галимҗан Баруди изге Мәккә шәһәренә хаҗ кылырга бара. Бу сәфәрдә ул Истанбулны, Мисырны зиярәт итә, галимнәр белән очраша, белемнәрен арттыра.Казанга кайткач, Галимҗан хәзрәт иске иҗек ысулын аваз ысулына алыштыра, уку-укыту программасын камилләштерә, яңа дәреслекләр, китаплар яза. Галимҗан Барудиның беренче китабы «Гильм әт-тәүхид» («Аллаһның берлеге турында гыйлем») 1890 елда басыла. 1891 елда яңа ысул белән укыту өчен «Сәвадхан» («Гыйлем иясе») исемле әлифба төзи.1906–1908, 1913–1917 елларда Галимҗан Баруди татар телендә «Әд-дин вәл-әдәп» исемле фәнни һәм дини журнал чыгара. 1908 елда Галимҗан хәзрәтне панисламизмда гаепләп, ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәрәләр. Анда 4 ай яшәп, Эчке эшләр министрлыгыннан чыгу өчен рөхсәт ала. Чит илләргә сәяхәт кылып, Вена, Будапешт, Истанбул, Димәшкъ, Бәйрут кебек шәһәрләрдә булып кайта. 1917 елның май аенда Мәскәүдә I Бөтенрусия мөселман корылтае уза. Күпчелек тавыш белән Русия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте мөфтие итеп Галимҗан Баруди сайлана.Галимҗан хәзрәт мөфти буларак күп хезмәтләр башкара, халыкка армый-талмый хезмәт итә, үлеме дә изге юлда йөргәндә була. Мөфти хәзрәтләре 1921 елның 6 декабрендә Мәскәү каласында ачларга ярдәм күрсәтү эшләре белән командировкага барган чакта вафат була. Аны Казанга кайтаралар һәм Яңа татар бистәсе зиратына күмәләр.

**Галимджан Баруди** (наст. фамилия Галеев; 17 февраля 1857, деревня Малые Ковали (Высокогорский район), Казанская губерния, Российская империя — 6 декабря 1921) — российский татарский учёный-богослов, религиозный и общественный деятель, педагог. Родился в семье торговца. Когда ему было три года, его семья переехала в Казань. В 1862 году начал учиться чтению и письму в медресе Казани. В 1875 году уехал в Бухару для продолжения своего религиозного образования. В 1882 году вернулся в Казань, где стал вторым имамом в Белой мечети, за короткое время значительно преуспев по службе и увеличивая круг учеников, ввиду чего Диния в 1883 году позволила ему основать своё медресе. Баруди сделал это практически сразу же, дав новому медресе имя своего отца — «Мухаммадия». Вскоре его медресе становится крупным и престижным духовным училищем Казани. В 1887 году предпринял длительную поездку в Османскую империю и Египет.

С 1905 года Баруди практически полностью посвятил себя педагогической деятельности, писал учебники, активно публиковался в печати, расширял и совершенствовал учебную программу своего медресе, а число учеников в нём и авторитет созданной им мусульманской школы ещё более выросли. В 1906 году Баруди основал и возглавил журнал «ад-Дин ва-ль-адаб» (рус. «Религия и нравственность»), издававшийся в Казани, который был запрещён властями в 1908 году. В том же году Баруди был обвинён в распространении панисламистских взглядов и сослан в Вологодскую губернию. В 1913 году вернулся из ссылки и возобновил издание своего журнала до 1917 года.

Баруди также был активным деятелем мусульманского движения в Российской империи в целом. В частности, в январе и августе 1906 года он участвовал в работе 2-го и 3-го съезда мусульман России, был членом комитета правления мусульманской организации «Иттифак аль-муслимин». 1-2 мая 1917 года на Всероссийском съезде мусульман в Москве большинством голосов Динии был избран муфтием. Баруди умер в Москве в 1921 году, в последние месяцы жизни активно участвуя в работе комитета по помощи голодающим Волго-Уральского района.

Похоронен на Татарском кладбище Казани.

# Хәй Вахит



Хәй Вахит (Габделхәй Каюм улы Вахитов) 1918 елның 2 декабрендә Казан губернасы Арча өязе (хәзерге Татарстан АССРның Биектау районы) Мәмдәл авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1934 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп, Театр техникумына укырга керә. Ләкин ике елдан соң техникум ябылу сәбәпле укуын өзәргә мәҗбүр булып, хәзерге Чистай районының Яңа Роман авылына укытучы булып китә, аннары янә Казанга килеп, 1937—1940 елларда музыка училищесында укый. Училищены тәмамлап, бераз вакыт Республика җыр-бию ансамблендә җырчы булып эшләгәннән соң, 1941 елда Х. Вахит армиягә алына. Ул башта Совет Армиясе җыр-бию ансамблендә җырчы булып хезмәт итә, соңыннан разведчик-артиллерист сыйфатында Белоруссия фронтында барган каты сугышларда катнаша, совет гаскәрләре белән бергә Польшага хәтле сугышчан юл уза.1945 елның ноябрендә армиядән кайтып, Х. Вахит Казан дәүләт консерваториясенең теория-тарих факультетына укырга керә һәм аны 1951 елда тәмамлап чыга. 1956—1958 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Шул вакыттан алып гомеренең соңгы көннәренә каңәр ул, профессиональ язучы буларак, фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Х. Вахит сугышка кадәр үк яза башлый. 1938—1939 елларда аның бер-бер артлы «Соры кортлар» исемле пьесасы һәм «Дулкыннар» дигән шигырьләр җыентыгы басылып чыга, «Канлы куллар» дигән пьесасы исә 1939 елда Минзәлә колхоз-совхоз театры репертуарына кертелеп, сәхнәдә уйнала. Х. Вахит бу елларда шулай ук балалар өчен шигырьләр һәм халык иҗаты материалларына нигезләп озын-озын поэмалар да яза («Әкиятләр» җыентыгы, 1940). Балалар әдәбиятына игътибар әдипнең сугыштан соңгы иҗатында да берникаңәр вакыт дәвам итә: илленче елларда аның балалар өчен бер-бер артлы «Безнең авылда», «Якты юл» һәм рус телендә «Весна идет» исемле шигырь җыентыклары дөнья күрә.

Ләкин Х. Вахитны язучы итеп таныткан җанр — драматургия. Аның «Беренче мәхәббәт» (1960), «Рәхим итегез!» (1961), «Кайда соң син?» (1963), «Карлыгач канат кага» (1965), «Соңгы хат» (1966), «Кук капусы ачылса» (1967), «Туй алдыннан» (1969), «Мәхәббәтең чын булса» (1972), «Давыл» (1973), «Ике килен-килендәш» (1976), «Ялгышасың, Нәзирә!» (1976), «Онытa алмасаң нишләрсең» (1977) кебек пьесалары, алтмышынчы-җитмешенче еллардагы татар театрлары репертуарының төп исемлегендә йөреп, шул чор татар драматургиясенең, театр сәнгатенең олы бер казанышы буларак тәкъдир ителә. 1960 елда «Беренче мәхәббәт» драмасы буенча Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган спектакль өчен әсәрнең авторы Х. Вахит һәм Режиссер Рифгать Бикчәнтәев Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булалар.Х. Вахит опера либреттолары һәм музыкаль комедияләр авторы буларак та билгеле. Аның «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир», «Наемщик» (Т. Гыйззәт драматик поэмасы буенча) дигән опера либреттолары һәм «Мәхәббәт җыры», «Кияүләр» (1975) исемле музыкаль комедияләре бар. «Җиһангир» либреттосының Бөтенсоюз конкурсында җиңеп, бүләккә лаек булуы Х. Вахитның бу жанрда да уңышлы эшләвен күрсәтә.

Х. Вахит 1978 елның 7 июлендә вафат була.

Хай Вахит (Вахитов Абдулхай Каюмович) родился 20 декабря 1918 года в деревне Мемдель (Мәмдәл) Казанского уезда Казанской губерны (ныне Высокогорский район Татарстана) в среднедостаточной семье крестьянина. Еще в детстве он лишился обоих родителей и остался на попечении родственников.

Несмотря на тяжелую жизнь, будущий драматург интересовался литературой и мечтал связать свою жизнь с искусством. Все это привело его сначала в Казанский театральный техникум, а потом в музыкальное училище, по окончании которого Хай Вахит устроился на работу в республиканский ансамбль песни и пляски. В эти годы начинается активная творческая деятельность Хая Вахита как драматурга. В 1937 году были написаны и вскоре опубликованы его первые пьесы "Канлы куллар" ("Кровавые руки") и "Соры кортлар" ("Трутни"). В 1939 году вышел первый сборник его стихов под названием "Дулкыннар" ("Волны").

Великую Отечественную войну драматург начал со службы в Ансамбле песни и пляски Красной Армии, а закончил разведчиком бронепоезда. Потом учеба в Казанской консерватории, на Высших литературных курсах в Москве. Именно в эти годы восходит звезда Хая Вахита как драматурга. В 1950-1960-х гг. на сцене Татарского государственного театра им. Г.Камала с неизменным успехом шли ею пьесы: "Беренче мәхәббәт" ("Первая любовь") — в 1961 году она была удостоена Государственной премии ТАССР им. Г. Тукая и принесла драматургу широкую известность, "Рәхим итегез!" ("Добро пожаловать!"), "Кайда соң, син?" ("Где же ты?"), "Соңгы хат" ("Последнее письмо"), "Күк капусы ачылса" ("Если улыбнется счастье") и др.

Одновременно с работой над пьесами, Хай Вахит пишет либретто к операм "Самат" и "Дим буенда" ("На берегу Демы"). Работа над либретто к опере "Жиһангир" ("Джигангир", 1976) стала одной из последних работ Хая Вахита. Умер драматург в Казани 7 июля 1978 года.

**Уңган сыерчык**

*Хәй Вахит*

Ак буяулы бер оя бар
Бакчада зур агачта,
Очып килә шул ояга
Сыерчык яз булгач та.

Шунда тора, шунда йоклый,
Шунда бала үстерә,
Матур итеп сузып сайрый
Басып оя өстенә.

**Туган илебез**

*Хәй Вахит*

Без — бәхетле, шат балалар,
Без кайгыны белмибез,
Эх, ямьле соң, күңелле соң
Безнең Туган илебез!

Болыннарда, бакчаларда
Уйнап-җырлап йөрибез.
Эх, киң дә соң, иркен дә соң
Безнең туган җиребез.

Нурлар белән, гөлләр белән
Бизәлгән һәр көнебез.
Эх, зур да соң, матур да соң
Безнең Туган илебез.



**Солтан Габәши**

1891 елда Казан губернасы Казан өязе Алат волостеның Солабаш, ягъни хәзерге Татарстанның Биектау районы Кече Солабаш авылында җәдит мулла Хәсәнгата Габәши гаиләсендә туган ул. «Мөхәммәдия» (Казан) һәм «Галия» (Уфа) мәдрәсәләрендә укыганнан соң, ул Уфа һөнәр училищесында белем алуын дәвам иттерә. Солтан кечкенә вакытында ук кубызда, гармунда халык көйләрен уйнарга өйрәнә. Музыкага сәләтен күреп, әтисе аңа укытучы чакыра. Берничә ел музыка гыйлеме буенча дәресләр алу аңа зур ярдәм итә. Уфа мәдрәсәсендә укыганда ук С. Габәши музыкаль кичәләрдә катнаша, пианист-аккомпаниатор буларак чыгышлар ясый. Солтан көй язу өлкәсендә дә үзен сынап карый. 1913-1915 елларда ул үзенең беренче оригинал әсәрләрен яза (“Кәккүк”, “Рөкыя-гөлкәем”, “Вальс”, “Пикник”, “Татар кызы”).

1915 елда С. Габәши Казанга кайта һәм университетның юридик факультетына укырга керә. Ике ел укыгач, аны армиягә алалар. Казанда аның музыка буенча эшчәнлеге тагын да активлаша. С. Габәши татар драма труппасының берничә спектакленә (Г.Исхакыйның “Зөләйха”, Ф.Бурнашның “Таһир-Зөһрә”, К.Рәхимнең “Бүз егет” әсәрләре) музыкалар яза. Актуаль темага язылган җырлары, “Яңалиф маршы” үз вакытында халыкка киң танылa. Композиторның “Кәккүк” романсы – шулай ук халык мәхәббәтен казанган әсәрләрнең берсе.

20 нче елларда Татарстанда татарча професиональ музыкаль белем бирү барлыкка килә. С. Габәши музыка белеме бирүче беренче укытучылар сафында була: хор дәресе, музыка теориясе буенча укыта. Казан музыка техникумы директоры урынбасары булып эшли. Татарстан районнарына фольклор экспедицияләренә чыга.

Республикабыз музыка сәнгате өчен бөтенләй яңа булган хор сәнгатенең үсешенә С.Габәши аеруча зур өлеш кертә. Шул максатны күздә тотып, ул татар халык җырларын катнаш хор белән башкару өчен эшкәртә. Әлеге әсәрләр яңа гына оешкан бик күп хор коллективларының төп репертуарын тәшкил итә.

Газиз Әлмөхәммәтов һәм Василий Виноградов белән берлектә, Солтан Габәши беренче татар опералары “Сания” (1925) һәм “Эшче”не (1930) иҗат итүдә катнаша.

1932 елда С.Габәши Уфага күчеп китә, Башкорт сәнгать техникумында укыта, Башкортстан Композиторлар берлеген оештыручыларның берсе булып тора.

С.Габәши 1942 елның 8 гыйнварында Борай районында сөргендә вафат була.

Султан Габяши (настоящее имя Габяши Султан-Ахмет Хасангатович) родился 1 мая 1891 года в деревне Малый Сулабаш Дубьязовского уезда Казанской губернии, ныне Высокогорского района Республики Татарстан. Рос и воспитывался в обеспеченной и образованной семье религиозного деятеля Хасангаты Габяши (1863-1933), основателя новометодной школы в родном селе.
Султан Габяши обучался в медресе «Мухаммадия» в Казани, затем продолжил образование в уфимском медресе «Гусмания», позже в Уфимском реальном училище и знаменитом медресе «Галия». В Уфе Султан берет уроки игры на фортепьяно у педагога Нины Соколовой, принимает участие в концертах татаро-башкирской музыки, выступает со своими музыкальными сочинениями, читает лекции, пишет статьи о национальной музыке. В 1915 году вместе с родителями Султан Габяши переехал в Казань. В 1916-1917 годах учился на юридическом факультете Казанского университета. Султан Габяши активно участвует в культурно-музыкальной жизни Казани, выступает как аккомпаниатор, ведет уроки музыки, руководит школьными хорами.
Однако вскоре в казанской печати появляются статьи с критикой Султана Габяши как сына «служителя культа», он голословно обвиняется в панисламизме и пантюркизме. В 1932 году композитор был вынужден переехать в Уфу, чему способствовал его друг и соратник Газиз Альмухаметов.
В Уфе Султан Габяши работал сотрудником Башкирского НИИ национальной культуры (ныне Институт истории, языка и литературы УНЦ РАН), одновременно преподавал в Башкирском техникуме искусств (ныне Уфимское училище искусств). В эти годы Султан Габяши активно участвовал в создании Башкирского отделения Союза композиторов СССР и стал одним из первых ее членов. Выходит в свет сборник «10 интернациональных песен» на башкирском языке под музыкальной редакцией Султана Габяши. Он подготовил сборники «Песни фабрик и заводов» и «Красноармейские песни», В 1937 году Султан Габяши вместе с музыковедом Львом Лебединским работал над записями башкирских песен. В 1940 году он заключил договор с московским композитором Николаем Чемберджи о совместной работе над музыкой балета «Сынграу торна». Композитор Антон Эйхенвальд предлагал ему вместе поработать над оперой «Ашкадар». Но этим планам не было суждено сбыться.
С 1941 года Сулпан Габяши являлся учителем Челкаковской средней школы Бураевского района, куда был вынужден переехать из-за продолжающихся гонений и трудных бытовых условий в Уфе. В Челкаково Султан Габяши кроме работы в школе, где вел уроки пения, создал духовой оркестр, организовывал концерты и спектакли.
Умер композитор 8 января 1942 года, находясь на тяжелых лесозаготовительных работах, на 51-м году жизни, и похоронен в Челкаково.



**Рафис Корбан**

Балалар шагыйре һәм драматургы Рафис Корбан (Корбанов Рафис Харис улы) 1957 елның 1 гыйнварында Татарстанның Дөбъяз (1965 елдан Биектау) районы Кече Битаман авылында туган. Башлангыч белемне туган авылында ала, аннары күршедәге Зур Битаман авылында урта мәктәпне тәмамлагач, 1974 елда Казан университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1977 елда университетның өч курсын тәмамлап, «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясенә эшкә урнаша, икенче елны Буага китеп, ике елга якын «Байрак» исемле төбәк газетасында эшләп ала. 1980 елдан ул янәдән Казанда: шәһәрнең автозаправкалар идарәсендә рәссам, 1982 елдан 1989 елга кадәр Татарстан радиосында әүвәл музыкаль тапшырулар, аннан балалар өчен тапшырулар һәм әдәби тапшырулар редакцияләрендә эшли. 1989 елдан соң төрле газета-журнал редакцияләрендә — «Салават күпере»ндә, «Идел»дә, «Әдәби җомга» газетасында, Татарстан язучыларының әдәби фонды идарәсендә, төрек-татар газетасы «Заман»да, «Шәһри Казан»да төрле җаваплы вазифаларны башкара, Казан дәүләт курчак театрының әдәби бүлек мөдире, «Мәгариф» милли нәшрияты мөхәррире, Татарстан китап нәшриятының китап тарату бүлеге мөдире хезмәтендә була. Хәзерге вакытта Рафис Корбан Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият һәм балалар әдәбияты редакцияләрен җитәкли.Р.Корбан башлангыч мәктәптә укыганда, тугыз яшьләрендә чакта ук каләм тибрәтә башлый. Җиденче сыйныфта укыганда (1971 ел) «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында шагыйрь Мәхмүт Хөсәен фатихасы белән «Таң көтеп» дигән беренче шигыре басылып чыга. Шуннан соң «Яшь ленинчы»да, «Ялкын» журналында, Биектауда чыга торган район газетасында бер-бер артлы шигырьләре, хәбәрләре, рәсемнәре басыла башлый. Студент елларында, әдәби мохиттә кайнаучы яшь каләмдәшләре киңәше белән, ул тулы-сынча балалар өчен язуга күчә. Ниһаять, 1987 елда аның кече яшьтәге балалар яратып кабул иткән «Буран кайда йоклый?» исемле беренче китабы дөнья күрә. Шуннан соң ике елдан «Җиде төстә кунакта» исемле икенче китабы, аннан «Сөзгәк болыт» (1991), «Капкорсак» (1992), «Капкорсак һәм Бавырсак» (1993) һәм башка шигъри җыентыклары нәшер ителә. «Капкорсак» китабы өчен автор 1993 елда Шәйхи Маннур исемендәге әдәби бүләккә лаек булды. Ул - шулай ук Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге бүләк иясе дә(2003).Рафис Корбанның балалар драматургиясе, бигрәк тә курчак театрлары репертуарын баету юнәлешендәге иҗади эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Казан курчак театры аның «Куркуын җиңгән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1995), «Ак күлмәктә кара елан» (1996) исемле пьесаларын сәхнәләштерде, «Керпе малае дуслар эзли» дигән пьесасы 1995 елда Татар дәүләт яшьләр театры сәхнәсендә куелды, Чаллы курчак театрында «Куркуын җиңгән Куян» (1998), Уфадагы «Нур» татар театры һәм Чаллы татар драма театры сәхнәләрендә «Патша кызы һәм җырчы» (2001) исемле пьесалары уңыш казанды. Язучының сәхнә әсәрләре 2000 елда Татарстан китап нәшриятында «Куркуын җиңгән Куян» исеме белән чыккан җыентыгында урын алган.Р.Корбан лирик һәм публицистик шигырьләр, җыр текстлары авторы буларак та билгеле («Уян, татар!» — 1999; «Яра» — 2004).

Курбанов Рафис Харисович (Рафис Курбан) родился 1 января 1957 года в деревне Малый Битаман Высокогорского района Татарстана. После окончания Большебитаманской средней школы учился на отделении журналистики Казанского государственного университета. Еще в студенческие годы он сотрудничал с газетой «Татарстан яшьләре», являясь корреспондентом отдела школ и вузов редакции. После окончания третьего курса устроился на работу в Буинскую районную газету «Байрак», где проработал около двух лет корреспондентом сельхозотдела.
В 1980 году Р.Курбан вернулся в Казань и до 1982 года работал художником-оформителем в Управлении автозаправочных станций города.
В 1982–1989 годах он был редактором в Государственном комитете ТАССР по телевидению и радиовещанию, в 1989 году – ответственным секретарем журнала «Салават күпере», в 1990 году – «Идель», в 1991–1993 годах – главным редактором газеты «Мәдәни җомга», в 1993 году – турецко-татарской газеты «Заман», с 1993 по 1995 год – заведующим литературно-драматической частью Казанского театра кукол, редактором издательства «Магариф».
С 1996 года Р.Курбан работал в Татарском книжном издательстве, где в 1999 году возглавил редакцию художественной и детской литературы, а в 2007–2008 годах работал главным редактором Татарского книжного издательства.
Р.Курбан начал печататься в школьные годы на страницах детских журналов и газет.
В 1987 году вышел его первый сборник стихов для детей «Буран кайда йоклый?» («Где спит буран?»). Он автор более 20 книг для детей: «Сөзгәк болыт» («Бодливая тучка», 1991), «Капкорсак» («Пузатый», 1992), «Алмалы төн» («Книга малышей», 2002) и др.
В середине 90-х годов, в период работы в Казанском театре кукол, Р.Курбан написал ряд детских пьес. На сцене кукольных театров Казани и Набережных Челнов с успехом шли его пьесы «Куркуын җиңгән Куян» («Заяц, победивший страх», «Бардым күлгә, салдым кармак» («Закинул я удочку», «Керпе малае дуслар эзли» («Ёжик ищет друзей»). Пьеса «Патша кызы һәм җырчы» («Царевна и певец») была поставлена на сценах Уфимского татарского театра «Нур» и Набережночелнинского татарского драматического театра. Лучшие сценические произведения писателя для детей опубликованы в сборнике «Заяц, победивший страх» (2000).
Р.Курбан известен и взрослому читателю как автор замечательных книг лирико-публицистических стихов («Уян, татар!» («Проснитесь, татары!», 1999) и «Яра» («Рана», 2004)). Многие его лирические произведения вдохновили татарских композиторов на создание песен, которые впоследствии стали популярными в народе.
Творческие достижения Р.Курбана отмечены двумя литературными премиями Союза писателей Татарстана имени Ш.Маннура (1993) за книгу «Пузатый» и А.Алиша (2003) за книги «Заяц, победивший страх» и «Книга малышей».
2006 году Р.Курбану присвоено почетное звание «Заслуженный деятель искусств Республики Татарстан».
С 1990 года – член Союза писателей Татарстана.

Биектау
*Рафис Корбан*

Биектауның биек таулары юк,
Биектауда биек үрләр бар.
Биектауның данын биекләргә
Алып менгән бөек ирләр бар.

Ул- бишеге татар моңнарының.
Анда туган Солтан Габәши.
Шушы якның караңгы бер авылы
Биргән җиргә Салих Сәйдәшне.

Халкым минем кара заманнардан
Каралыплар беткән бер чорда,
Агартырга теләп халык аңын
Максудилар туган Ташсуда.

Халкымның күңеле пакь булса да.
Кара  заманнары бар иде.
Агартырга теләп халык аңын
Безнең яктан чыккан Баруди.

Туган якны сагынып, якташларны
Уйлап йөргән чакта кайвакыт,
Искә килеп төшә иҗатында
Күк капусын ачкан Хәй Вахит.

Ахры, монда мәңге бетмәс моңнар.
Кайтара шул моңнар чакырып.
Әлдермешнең Әлмәндәре кебек
Аксакалы – Әнвәр Бакиров.

Бармагымны бәгә-бөгә саныйм
Бөекләрен туган ягымның.
Шушы якта тамырларын җәйгән
Шәҗәрәсе Рөстәм Яхинның.

Горурланып атыйм исемнәрен!
Гөнаһ түгел алу макташып.
Кем генә соң горурланмас иде
Сәйдәшевнең булса якташы?!

Безнең якны Казан арты, диләр,
Даны олы  безнең якларның.
Еракларда йөри аның даны,
Даны булып йөри татарның.



**Зиннур Хөснияр**

Язучы Зиннур Хөснияр (Зиннур Зыятдин улы Хөснетдинов) 1961 елның 18 июлендә Татарстан Республикасының Биектау районы Бикнарат авылында туа. Әтисе Зыятдин ага – балта остасы, тимерче, әнисе Һәдия ханым авылның күмәк хуҗалыгында хезмәт итә. 1978 елда туган авылыннан өч чакрым ераклыктагы Олы Битаман авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Зиннур Казан педагогия институтының тарих-филология факультетына укырга керә. Студент елларында институт каршындагы «Илһам» әдәби-иҗат түгәрәгенең актив әгъзаларыннан берсе була, соңга таба аны үзе үк җитәкли.Дүртенче курста укыганда «Ялкын» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире булып эшли башлый.1985–1987 елларда З.Хөснияр гаскәри хезмәттә, Брест шәһәрендә офицерлар әзерли торган мәктәпне тәмамлый. Армиядән кайткач, 1989 елның октябренә кадәр Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакциясе мөхәррире, аннары берникадәр вакыт Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. Шул ук 1989 елның ахырларында ул Татарстан Язучылар берлеге белән берлектә һәм «ПОИНТ» совет-фин уртак предприятиесе (җитәкчесе – эшмәкәр-журналист Солтан Сәлимҗанов) ярдәмендә татар балалары өчен төсле-бизәүле «Салават күпере» исемле журналга нигез сала һәм журналның баш мөхәррире итеп билгеләнә . Зиннур Хөсниярның матбугат мәйданындагы игелекле хезмәт башлангычлары бер «Салават күпере» басмасы белән генә чикләнми. 1997 елдан нәшер ителә башлаган «Таһир-Зөһрә» гаилә газетасы, 1999 елдан яшьләргә атап чыгарылган «Җүләр чак», өлкәнрәк укучыларны күздә тоткан «Яучы», медицинага кагылышлы «Әбүгалисина» газеталары һәм, ниһаять, 2001 елда нигезләнгән «Сәхнә» исемле театр һәм эстрада журналы – болар һәммәсе Зиннур Хөсниярның шәхси инициативасы һәм матди кайгыртуы белән, аның үз нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә дөньяга килгән басмалар. 2001 елдан әлеге газета-журналлар З.Хөснияр үзе оештырган «Ак барс» нәшрият йорты» тарафыннан басып таратылалар. З. Хөснияр «Ак болыт күләгәсе», «Хуҗа һәм аның хатыны», «Кышлаган үгез» исемле хикәяләре өчен 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге премиясе белән бүләкләнде.2005 елда нәшер ителгән «Два билета на трагедию» (2007) китапларында автор бүгенге яшәешнең төрле якларын ачуын дәвам итә. «Хуш, авылым!», «Гарасат» кебек романнарда Хөснияр авыл җиренә, гади эшче халыкка дан җырлый.З.Хөснияр – татар балалар әдәбияты өлкәсендә дә иң актив авторларның берсе. 1996–2004 еллар арасында аның кече яшьтәге балалар өчен биш китабы басылып чыкты.Тормыш иптәше Нурия белән Зилә һәм Булат исемле балалар тәрбияләгәннәр.Зиннур Хөснияр – Ш.Маннур, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр, М.Җәлил исемендәге Республика яшьләр премиясе (2006), әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты (2008), Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» мактаулы исеме (22.03.2001 ел, ТР Президенты Указы), «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале (2005), Татарстан Президенты Р.Миннихановның «Рәхмәт хаты» иясе (2010), ТРның Язучылар берлеге әгъзасы (1990), ТРның Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (2016).

Писатель-прозаик, Зиннур Хуснияр родился 18 июля 1961 года в деревне Бикнарат Высокогорского района Республики Татарстан. Закончил Казанский государственный педагогический институт отделение татарского языка и литературы. В студенческие годы был одним из активнейших участников институтского литературно-творческого кружка «Илһам» («Вдохновение»), позже стал его руководителем. Писал рассказы, повести, некоторые из них потом были включены в первый его сборник «День за днем» («Таң ата да кич була»), вышедший в 1989 году.

В октябре 1989 года по инициативе З.Хуснияра открывается недотационный журнал для детей «Салават күпере» («Радуга»), главным редактором которого он является до сего дня. В 1977 году он учреждает семейную газету с большим тиражом «Таһир-Зөһрә», а через год – молодежную газету «Җүләр чак», медицинскую газету «Әбүгалисина», социально-бытовую газету «Яучы» («Сваха»). В 2001 году З.Хуснияр открывает коммерческое издательство «Издательский дом «Ак Барс»», и все печатные издания, учрежденные З.Хуснияром, осуществляются этим издательством, директором которого он является.

На литературном поприще З.Хуснияр известен как автор многочисленных рассказов, ряда повестей и двух романов - «Война локтями», «Сын собачий», посвященных современным темам. Активно работает также в детской литературе, пишет рассказы, сказки, пьесы.

З.Хуснияр – член Союза писателей Татарстана (1990), заслуженный деятель искусств Республики Татарстан (2001), лауреат литературной премии имени Фатиха Хусни Союза писателей Татарстана (2001).

**Әнвәр Бакиров**



Танылган композитор Әнвәр Закир улы Бакиров 1920 елның 7 июлендә Казан шәһәрендә туа. Бала чагы Биектау районының Әлдермеш авылында уза. Музыкаль белемне башта Казан музыка училищесында ала. 1940–1946 елларда ул Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1952 елда Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый. Ә.Бакиров 1951–1956 елларда Казан музыка училищесында укыта, 1956–1957 дә Татар опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире, 1957–1970 елларда Казан, Алабуга балалар музыка мәктәпләрендә эшли.Ә.Бакиров – татар профессиональ музыкасына нигез салучы композиторларның берсе. Ул үз гомеренең 50 дән артыграк елын музыка сәнгатенә багышлый. Композиторның иҗаты жанр байлыгы белән аерылып тора. Ул – ике балет, музыкаль комедияләр, «Тукай» операсы, симфоник, хор әсәрләре, камера-инструменталь музыкасы һәм 200 дән артыграк җыр авторы. Аның «Тальян моңы» музыкаль комедиясе, виолончель өчен сонатина һәм «Иртәнге серенада», «Әйткән идең», «Әй кызлар» һ.б. моңлы җырлары халыкка киң таныла. Композитор Ә.З.Бакиров уку-агарту эшенә, республиканың музыка һәм иҗтимагый тормышына үзеннән күп өлеш кертә. Ул – музыка буенча татар телендәге «Җыр һәм музыка дәресләре» дигән беренче дәреслек авторы да.

Ә.З.Бакиров иҗатына лаеклы бәя бирелә. Аның «Су анасы» балеты 1973 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Татар музыка сәнгатен үстерүгә керткән хезмәтләре өчен Ә.Бакировка Татарстан АССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә.Әнвәр Закир улы Бакиров 2001 елның 17 августында вафат була.

**Энвер Закирович Бакиров** (тат. *Әнвәр Закир улы Бакиров*; 7 июля 1920, Казань — 10 августа 2001, Казань) — советский и российский композитор, заслуженный деятель искусств Татарской АССР (1969), РСФСР (1981), лауреат Республиканской премии имени Габдуллы Тукая (1973), народный артист Республики Татарстан (1993).

Детство писателя проходит в деревне Альдермыш Высокогорского района. В 1940 году окончил Казанское музыкальное училище, где по классу училище), по классу композиции — у Юрия (Георгия) Васильевича Виноградова, 1907 года рождения, советского композитора и музыковеда, Заслуженного деятеля искусств ТАССР с 1954 года.В 1940—1946 проходил службу в вооружённых силах, уволился в звании гвардии лейтенанта. В 1942 году окончил Ульяновское высшее танковое командное училище имени В. И. Ленина.В 1952 году окончил Казанскую государственную консерваторию по классу композиции, курс профессора Альберта Семёновича Лемана. В 1951—1956 годах преподавал в Казанском музыкальном училище. В 1956—1957 годах работал заведующим литературной частью Татарского театра оперы и балета имени Мусы Джалиля. В 1958 году Бакиров построил и открыл музыкальную школу № 1 в городе Елабуга, которая в настоящее время носит его имя. В 1957—1970 годах работал в детских музыкальных школах Казани, Елабуги, руководил коллективами художественной самодеятельности в Казани, Мензелинске, Набережных Челнах.

Началом творческой деятельности Бакирова принято считать песню «Иртәнге серенада» (Утренняя серенада) (стихи Хәй Вахита, первый исполнитель Нияз Даутов), написанная в 1937 году. Песня стала одним из наиболее популярных произведений. За свою творческую жизнь Энвер Бакиров написал более двухсот песен, которые стали истинно народными. Для творчества композитора характерен широкий диапазон жанров.

Одним из наиболее значительных произведений Бакирова является балет «Алтын тарак» («Золотой гребень», 1957 год), в новой редакции — «Су анасы» («Водяная», 1971 год), по мотивам одноимённой сказки Тукая. Этот балет является одним из самых популярных татарских балетов. В 1982 году им, в соавторстве с Ахметом Исхаком, завершена работа над оперой «Тукай», она принята Министерством культуры ТАССР к постановке, на основании заключения и рекомендации к постановке Секретариата Союза композиторов РСФСР. К сожалению, она до сих пор не поставлена. Оба автора этого произведения, посвященного личной жизни Великого татарского поэта Габдуллы Тукая, уже ушли из жизни. Арии из этой оперы звучат только в концертном исполнении. Певцы, впервые исполнившие их когда были студентами Татарской консерватории, уже и сами состарились. А опера так и лежит на «полках» Татарского театра оперы и балета имени Мусы Джалиля.



**Сәлих Сәйдәшев**

Ул татар профессиональ музыкасының әтисе дип санала. Ул чын профессиональ, югары иҗади дәрәҗәдә беренче композиторлар тәҗрибәсен, нәтиҗәләде, купъеллык халык традицияләрен европа музыкасы тәҗрибәсе белән берләштерде, һәм бу нигездә чын милли профессиональ сәнгатьне оештырды. Ул – бөек татар композиторы Сәлих Сәйдәшев.

Сәйдәшев Сәлих Замаледин улы 1900нчы елның 3 декабрендә Казанда туа. Сәлихның бабасы Бикчәнтәй Биектау районы Ибрә авылыннан була. Музыкаль таланты яшь чагыннан ук сизелә. Аның беренче укытучысы халык музыканты Загидулла Яруллин була, а соңырак Казан музыка училищесының күренекле педагоглары.

1918нче елда яшь музыкант оркестр оештыра. 1920нче елда ул Кызыл Армия рәтләренә уз теләге буенча керә, ә аннан кайтуга Оренбургның музыка мәктәбендә хезмәт итә.

1922нче елда Сәлих Казанга кайтып, Камал исемендәге Дәүләт академик театрында дирижер һәм музыкаль җитәкче буларак эшли башлый. Аның иҗади эшчәнлеге төрле якларга тарала – бер-бер артлы “Галиябану”, “Башмагым”, “Ил”, “Зәңгәр шәл” музыаль әсрләре килеп чыга. Ул музыкаль драма жанрында С. Габяши эзләре буенча китә.

Шул ук елларда ул “Советлар Армиясе маршын” яза, яңа музыкаль әсәрләр ясау өстендә эшли, пианист һәм дирижер буларак төрле концерларда чыгыш итә.

1934-1938нче елларда Сәлих Сәйдәшев Мәскәүдә татар опера студиясендә белем ала. Мәскәүдән кайтуга ул Галиәскәр Камал театрында эшен дәвам итә, яңа әсәрләр яза, спектакльләргә музыканы яза.

1954нче елның 16 декабрендә Салих Сайдашев вафат була

Салих Замалетдинович Сайдашев родился 3 декабря 1900 г. в Казани.Дед Бикчантай был из деревне Ибря Высокогорского района. Рано лишившись родителей, он воспитывался в семье старшей сестры, муж которой Шигаб Ахмеров принадлежал к прогрессивным кругам татарской интеллигенции. После окончания начальной школы мальчик некоторое время получает уроки игры на фортепьяно у народного музыканта-самоучки Загидуллы Яруллина, а затем у видных педагогов Казанского музыкального училища, уже тогда одного из высокоавторитетных музыкальных учебных заведений Поволжья.

Сайдашев с первых дней после победы Октябрьской революции активно включается в дело культурного строительства — по предложению Буинского отдела просвещения создает музыкальную студню, при которой организует татарский и чувашский хоры для разучивания на родных языках первого гимна многонациональной Страны Советов— «Интернационала», затем добровольно вступает в ряды Рабоче-Крестьянской Армии, где служит трубачом, капельмейстером. С 1922 г. начинается новый и наиболее плодотворный период его творческой деятельности в качестве композитора, дирижера и заведующего музыкальной частью татарского театра. К этому времени молодой музыкант уже имел довольно солидную для своего времени музыкальную и организаторскую подготовку.В этот период Сайдашев активно трудится над созданием новых и новых музыкальных произведений в различных жанрах, выступает как пианист и дирижер на многочисленных концертах. Важное место в творчестве Сайдашева занимает песня — жанр, получивший невиданное развитие после революции. Достаточно напомнить его «Песню Советской Армии» на слова А. Файзи, «Песню советской молодежи» на слова А. Исхака, «Песню о дружбе», полную трудового энтузиазма песню на слова А. Ерикеева «Мы — строители»... И наконец, легендарный «Марш Советской Армии». Произведения Сайдашева всегда поэтичны, -возвышенны и обращены к сердцам слушателей. Вместе с тем композитор талантливо решил проблему создания национального музыкального языка (его мелодического строя, гармонии, всех жанровых типов), принципиально обогатив национальную музыкальную лексику. Он создал высокохудожественные произведения вокальной и инструментальной музыки, которые открыли перспективные пути развития национального театра (оперы и балета), инструментальных жанров.  Его статьи в периодической печати свидетельствуют о четких, принципиальных творческих позициях автора, о широте постановки им актуальных проблем творчества и в целом проблем музыкального национального искусства. Еще в 1929 г. («Кзыл Татарстан», 1929, 10 августа) он один из первых в стране ставит вопрос о взаимообмене художественными ценностями между братскими народами страны. Он неоднократно с большой группой артистов, поэтов и писателей гастролировал в городах Приуралья, Поволжья, Казахстана, Средней Азии, что получило широкое отражение в периодической печати тех лет и было по существу новым начинанием в области культурного обмена между республиками нашей страны. За выдающиеся заслуги перед советским музыкальным искусством Салиху Замалетдиновичу Сайдашеву в 1939 г. было присвоено звание заслуженного деятеля искусств ТАССР и в 1950 г.— почетное звание народного артиста ТАССР. Скончался композитор в расцвете физических и творческих сил 16 декабря 1954 г.



**Рөстәм Яхин**

Рөстәм Яхин- күренекле татар композиторы, Татарстан Республикасы Дәүләт гимны авторы, СССРның халык артисты.
Рөстәм Яхин 1921 елның 16 августында Казанда туган. Ә бабасы Ситдыйк Биектау районы Киек авылыннан була .Балачактан музыкага тартылган, татар халык җырлары белән кызыксынган, аларны аның әнисе Мәрьям ханым яхшы белгән. Туганы, танылган җырчы Мәрьям Рахманкулова киңәше белән 13 яшендәРөстәм Яхин Казанның 1нче балалар музыка мәктәбенә укырга бара. Мәктәп директоры Р.Л.Поляков һәм фортепиано укытучысы А.В.Чернышева баланың сәләтен күреп, аңа укуын Мәскәүдә дәвам итәргә тәкъдим итә. Мәскәү музыка училищесында А.Г.Руббахның фортепиано сыйныфын тәмамлаганнан соң, 1941 елда Р.Яхин Мәскәү консерваториясенә имтиханнарын уңышлы тапшыра. Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, яшь музыкантны армиягә алалар. Сугыш беткәч, Рөстәм Яхин укуын Мәскәү консерваториясендә дәвам итә: пианист буларак – В.М.Эпштейн, композитор буларак профессор Ю.А.Шапорин сыйныфында шөгыльләнә. Мәскәүдә укыган еллары комозиторның профессиональ осталыгы һәм иҗади үсешендә зур роль уйный. Диплом эше буларак ул Фортепиано белән оркестр өчен концерт (беренче бүлек) тәкъдим итә, бу әсәр күпләрдә зур кызыксыну уята (1950 ел). Шул елда ук комозитор Казанга әйләнеп кайта, фортепиано концерты өстендә эшен дәвам итә һәм 1951 елда аның тагын ике бүлеген язып бетерә. Бу әсәр татар музыкасында фортепиано белән оркестр өчен беренче концерт була.1950–1952 елларда Р.Яхин Казан консерваториясендә белем бирә, алга таба гомерен исә ул музыка иҗат итүгә һәм концертларда чыгыш ясауга багышлый.
Рөстәм Яхин татар композитор мәктәбе үсешенә өлеш кертә. Ул – күренекле камера–вокаль һәм камера–инструменталь музыка остасы, татар җыры һәм романсын, милли–характерлы инструменталь миниатюра жанрларын яңа дәрәҗәгә күтәрүче. Камера–инструменталь иҗатында аның фортепиано өчен язылган әсәрләре аерым урын алып тора. Ул татар фортепиано осталыгы үсешенә көч куя, профессиональ белеме булган беренче татар композиторы һәм концертлар бирүче пианист була. Хәзер Р.Яхин фортепиано әсәрләре – татар пианистлары репертуарының “алтын фондын” тәшкил итә.
1987 елда Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында Р.Яхинның төрле әсәрләре көйләреннән торган “Фидаи” исемле балет куела. Пианист буларак Р.Яхин үзенең генә түгел, рус һәм чит ил классикларының да әсәрләрен яратып уйный.
Р.Яхинның “Туган ягым” җыры көе 1993 елда Татарстан Республикасының гимны итеп кабул ителә.
1972 елдан башлап һәрвакыт Р.Яхин Татарстан Композиторлар берлегенең идарә әгъзасы итеп сайлана. 1964 елда аңа ТАССРның атказанган сәнгать эшелеклесе, 1970 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1981 елда РСФСРның халык артисты, 1986 елда СССРның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә, 1959 елда Г.Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премиясенә, 1957 елда “Мактау билгесе” орденына, 1971 елда Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек була. .
Рөстәм Яхин 1993 елда Казан шәһәрендә вафат була.
Рөстәм Яхинның рояле Татарстан Республикасының милли музеенда тора

**Яхин Рустем Мухаметхазеевич**(1921—1993) известный татарский композитор, пианист и педагог, Народный артист СССР и РСФСР,Лауреат Государственной премии РТ им. Г. Тукая,Заслуженный деятель искусств Татарской АССР родился 16 августа 1921 года в Казани.А дед был из деревни Большой Куюк Высокогорского района.
Музыкой стал заниматься с тринадцати лет. Окончил Казанскую детскую музыкальную школу № 1 по классу преподавателя А. В. Чернышевой.
В 1937 году переехал в Москву, где учился в музыкальном училище при Московской консерватории на пианиста (класс А. Г. Руббаха),затем вернулся в Казань, где некоторое время работал пианистом — концертмейстером Татарского радиокомитета.
В 1942 году был призван в ряды Красной Армии. Во время войны служил стрелком в зенитно-артиллерийской дивизии, а затем в ансамбле песни и пляски Московского фронта ПВО пианистом-аккомпаниатором (1942—1945).
В 1950 году окончил Московскую консерваторию по классам композиции (у профессора В. А. Белого, затем Ю. А. Шапорина) и специального фортепиано у В. М. Эпштейна, после чего вернулся в Казань и в 1950—1952 годах преподавал в Казанской консерватории.Известен как первый татарский пианист-солист, активно занимавшийся концертно-исполнительской деятельностью.
Член Союза композиторов СССР с 1948 года. Неоднократно избирался членом правления Союза композиторов РСФСР, ТатАССР.Умер 23 ноября 1993 года. Похоронен на татарском кладбище в Ново-Татарской слободе Казани.
Яхин Рустем Мухаметхазеевич автор Государственного **гимна Республики Татарстан**, написал более 400 песен и романсов.Его мелодика органически связана с национальным фольклором.Композитор расширил возможности татарской музыки, развив в новых условиях традиции П. И. Чайковского и С. В. Рахманинова, европейских романтиков XIX века, импрессионистов. Через это знакомое инонациональный слушатель легче входит в богатый мир образов татарского искусства.

**Творчество:**

Сочинения для скрипки:
«Поэма», Соната, «Песня без слов», «Старинный напев».
Для хора — кантата «Идель» на слова Р.Хариса и обработки народных песен.
Сочинения для фортепиано:
Концерт для фортепиано с оркестром, Соната, Сюита (4 части), пьесы (более 20).

**Награды и достижения:**

Лауреат Государственной премии РТ им. Г. Тукая(1959)
Заслуженный деятель искусств Татарской АССР (1964)
Заслуженный деятель искусств РСФСР (1970)
Народный артист РСФСР (1981)
Народный артист СССР (986)
орден Трудового Красного Знамени (1971)
орден «Знак Почёта» (1957)
Медаль «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941—1945 гг.
Медаль «За оборону Москвы» (1945),
Медаль «За доблестный труд» (1970),
Медаль «Ветеран труда» (1982),
Медаль «70 лет Вооружённых Сил СССР» (1986),
Знак «Фронтовик 1941—1945».